# Нәсыйхәт

җомга
28
октябрь
2011 №10

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**




# КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Корбан нигездә Ибраһим галәйһиссәләм белән улы Исмәгыйль галәйһиссәләмгә барып тоташа. Аллаһы Тәгалә аларның иманнарын зур сынау белән сыный. Алар шул сынауны уңышлы үтеп, Аллаһы Тәгаләнең мактавына лаек булалар.**

Ибраһим галәйһиссәләм Нәмрут яккан уттан саусәламәт чыккач, ватанын һәм туганнарын ташлап, хәзерге Фәләстыйн җирләренә барып урнаша. Шунда аңа картлык көнендә Аллаһы Тәгалә «хәлим» – «йомшак табигатьле», дип макталган угыл бала насыйп итә. Ул гел Аллаһы Тәгаләдән изге бала бирүен сорый торган була. Малайга Исмәгыйль дип исем кушалар. Ибраһим галәйһиссәләм бала булу шатлыгына куанырга өлгерми, төшендә шул баланы корбан итәргә боерыла. Бу боерык вәхи яки туры әмер итү аркылы түгел, ә бер ишарә кылу рәвешендә генә була. Ләкин Раббысына буйсынып, Аның кушканнарын үтәргә әзер булган Ибраһим галәйһиссәләмгә шул да җитә. Ул бу боерыкны һич каушап, югалып калмыйча, камил иман, тулы буйсыну белән үзенең бурычы дип кабул итә. Ул бу эшкә һич ашыкмастан һәм Раббысына ачуланмыйча керешә. Әлбәттә, бу боерыкны үтәү Ибраһим галәйһиссәләмгә бик авыр була. Ул бит баласын сугышка яки аны үлем көтә торган башка бер урынга җибәрми, бәлки аны үзенең куллары белән корбан итәргә җыена. Нәрсә генә булмасын, Ибраһим галәйһиссәләм әлеге дәһшәтле боерыкны берсүзсез кабул итә һәм үзенең максатын Исмәгыйль галәйһиссәләмгә әйтеп, аның бу турыдагы фикерен беләсе килә. Ибраһим галәйһиссәләм чыннан да Аллаһы Тәгалә аңа үзе теләгән изге бала бирдеме икәнен белергә тели. Исмәгыйль галәйһиссәләм үзе дә Аллаһы Тәгаләнең әмеренә ихластан буйсынырга әзер икәнлеген белдергәч, үзенең догасы кабул булганлыгына Ибраһим галәйһиссәләмнең шиге калмый. Исмәгыйль галәйһиссәләм үзенең Аллаһының боерыгына буйсынырга әзер икәнлеген белгертеп кенә калмый, бәлки Аллаһының рәхмәте, Аллаһының ризалыгы Аның боерыкларын үтәүдә икәнлегенә бөтен барлыгы белән инана. Менә шул иманы аңа шундый авыр сынауны үтәргә көч-куәт бирә. Ул: «Әй әтием!

**(Ахыры 2нче биттә)**

## Яңалыклар

### МӘДРӘСӘ–ДИНИ ҮЗӘК

Мамадыш мәдрәсәсе уку йорты вазыйфасын алып бару белән генә чикләнми, бәлки дини үзәккә әверелә бара. Аның базасында күп санлы дини чаралар үтә: биредә авыл имамнары җыелышлары уздырыла, җәйге балалар җәйләүләре киң колач җәеп үткәрелеп килә, төрле мәҗлесләр, бәйрәм тантаналары оештырыла. Мәдрәсәдә 7 нче ноябрь көнне Корбан гаетенә багышланган дини - мәдәни чара узачак. Көн тәртибендә: дини җырлар, мөнәҗәтләр, төрле ярышлар, корбан итеннән бәйрәм табыны.

### “ШӘҺРИ КАЗАН” КУНАГЫ

13 октябрьдә Мамадыш мәдрәсәсендә “Шәһри Казан” газетасының баш мөхәррире Мансур Мортазин кунак булып китте. Ул мәдрәсәнең эшчәнлеге белән кызыксынды. Бүгенге вәзгыятьтә әлегедәй уку йортларының кирәклеген ассызыклады. Әхлакый тәрбиянең актуаль булуын әйтте.

### ВӘКИЛЛӘРЕБЕЗ СЕМИНАРДА

Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт, мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман хәзрәт һәм Мамадыш муниципаль район башлыгының ярдәмчесе Алена Смирнова Түбән Камада узган семинарда катнаштылар. Чарада төрле районнардан хакимият вәкилләре дәбар иде. Биредә мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында дини белем бирү ысуллары һәм үрнәкләре күрсәтелде. Бу үрнәкләрне башка муниципаль берәмлекләрдә дә тәҗрибә кылуны ассызыкладылар.

### МОХТАҖЛАР ЧИТТӘ КАЛМАДЫ

16 октябрьдә Мамадыш мәдрәсәсе мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән көченнән килгәнчә хәйрия эшен башкарды. Мәдрәсә хезмәткәрләре уку йорты исеменнән инвалидларга һәм мохтаҗларга бәрәңге һәм кабак өләштеләр. Ярдәмгә ихтыяҗлары булганнар чарадан канәгать. Мондый изге эшләр тагын кабатланыр дигән өметтә калдылар.

### ВЕТЕРАННАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

31 нче октябрьдә мәдрәсә бинасында шәкертләр һәм мөгаллимнәр Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннары белән очрашты. Өлкән буын вәкилләре чарада катнашучыларга үзләренең башларыннан кичкән вакыйгалар турында сөйләделәр. Ватанпәрвәрлек турында фикерләрен җиткерделәр. Аларга очрашу истәлеге итеп бүләкләр бирелде. Әңгәмә чәй өстәле артында да дәвам итте.

### ГОШЕР СӘДАКАЛАРЫН – МӘДРӘСӘГӘ

Мәдрәсәдә гыйлем алучы шәкертләргә ел дәверенә җитәрлек ризык туплау, укытучыларга хезмәт хакы түләү өчен финанс булдыру – гаять дәрәҗәдә авыр мәсьәлә. Шуңа күрә мәдрәсә халыкның ярдәменә мохтаҗ. Хөрмәтле райондашлар! Мәдрәсәбезне ятим итмик, аңар һәрвакыт ярдәм кулы сузыйк!

### УКУЛАР ГӨРЛИ

Мәдрәсәдә һәр елдагыча 1 нче октябрьдән кичке укулар башланып китте. Шәкертләр мәдрәсәгә теләп йөриләр. Алар арасында өлкән буын белән беррәттән яшьләр дә бихисап. Монда шулай ук төрле һөнәр ияләрен дә күрергә була: табиблар, укытучылар, тәрбиячеләр... Аларның барысын да дингә мәхәббәт берләштерә. Аллаһ аларга хәерле гыйлем насыйп итсен.

# КОРБАН ГАЕТЕ МӨБАРәК БУЛСЫН!

**(Ахыры. Башы 1нче биттә.)**

Син үзеңә боерылганны кыл, ә мине син, Аллаһ теләсә, сабыр итүчеләрдән табарсың», – дигән сүздән башканы әйтми. Бу вакыйгада ата да, угыл да сынала. Ата–Аллаһының кушуы белән улын корбан итәргә, ә улы – корбан булырга әзер була. Ләкин без беләбез, «Хаж» сүрәсенең 37-нче аятендә корбан малларының ите дә, каны да Аллаһы Тәгаләгә кирәк түгел икәнлеге хәбәр ителгән. Шулай булгач нигә Аңа кеше каны кирәк булсын?! Аңа безнең бөтен барлыгыбыз белән буйсынуыбыз, бирелүебез һәм куркуларыбыз кирәк. Ата-угыл сынауны уңышлы үткәч, Аллаһы Тәгалә аларның хәлләрен җиңеләйтә – Ибраһим галәйһиссәләмгә улы урынына корбан итеп, сарык бүләк итә. Менә шул көннән башлап бөтен пәйгамбәрләрнең атасы булган Ибраһим галәйһиссәләм милләтенә һәр елны корбан чалу йөкләнә. Без дә–Ибраһим галәйһиссәләм милләте. Аллаһы Тәгалә безнең дә иманнарыбызны шул рәвешчә сыный. Әгәр без дә Аллаһы Тәгалә кушканнарны һич карышмастан, берсүзсез үтәсәк, аның артыннан һичшиксез җиңеллек, шатлык килер. Ислам дине – тынычлык дине. Ибраһим галәйһиссәләм белән улы Исмәгыйль галәйһиссәләмгә бирелгән сынауның нигезендә нәкъ менә шул нәрсә ята. Аллаһ ризалыгы өчен чалына торган корбаннан аккан беренче тамчы кан белән бергә корбан хуҗасының гөнаһлары юылыр диелгән. Әлеге бәйрәм көннәрендә Аллаһы Тәгаләгәнең бөеклегенә, Исламның хак дин булуына тагын бер кат инанып мохтаҗларга, ятимнәргә, төрле бәла-казаларга юлыккан мөселман кардәшләребезгә хәлдән килгәнчә ярдәм кулы сузыйк, туганнарыбыз, күрше-күләннәребезнең хәлләрен белешик!

# КОРБАН ЧАЛА БЕЛӘСЕЗМЕ?



**Корбан бәйрәме — ислам дөньясында иң олы, мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе. Якынлашып килүче Корбан бәйрәме һәрберебезнең күңеленә дә иман нуры өстәсә иде. Бу көн безнең өчен кылган гөнаһларыбызның ярлыкануы, Аллаһ кушмаган гамәлләрдән тыелу, үзеңә һәм әйләнә-тирәдәгеләреңә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә шатлык бүләк итү көне буларак кадерле. Аллаһы Тәгалә корбан чалу турында болай дигән: “ Раббың ризалыгы өчен намаз укыгыл һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!” (108:2)**

Корбан чалу турында пәйгамбәребез Мөхаммәд (с. г. в.) әйткән: «Дөреслектә, бу көнебезне намаз уку белән башларбыз, аннан кайтып корбаннарыбызны чалырбыз. Шулай эшләгән бәндә сөннәтебезне үтәгән булыр».

**Корбан чалу**

Терлекне интектермичә, кыйблага каратып яткырырга кирәк. Ул аягында чакта корбан догасы укыла. “Әллаһүммә иннә саләәтии үә нүсүкии үә мәхйәәйә үә мәмәәтии лилләәһи раббил галәмиинә ләә шәриикә ләһ. Әллаһүммә тәкәббәл һәәзииһил удхийәтәә” – “Аллаһым, минем намазым вә гыйбадәтем вә тереклегем һәм үлемлегем барча галәмнең хуҗасы булган Аллаһ өчендер һәм Аның кодрәтенәдер. Аллаһы Тәгаләнең һич шәрике, тиңе юктыр. Аллаһым, бу корбанны кабул әйлә”.

**Корбан чалуга ният итү:** “Әй, Раббым! Ошбу хайванны Синең әмерең буенча чаламын. Әй, Раббым! Кабул кыл. Бисмилләһи, Әллаһү әкбәр!” – дип корбанлык бугазы киселә.

**“Корбан” нәрсәне аңлата?**

Ислам буенча корбан чалу – эре һәм вак мөгезле терлекне Аллаһының ризалыгы өчен бәйрәм көннәрендә чалу. Бу “Кәүсәр” сүрәсендә чагыла: “Раббының ризалыгы өчен намазны үтә һәм корбан чал”.

**Корбан чалу ислам диненДә нинди урын тота? Ул һәркем өчен дә мәҗбүрие? Ничек башкарыла ул?**

Мөселман кешегә ел саен корбан чалу вәҗибтер. Шулай да хәлләреннән килмәгәннәр өчен мәҗбүри дип саналмый. Аллаһының илчесе галәйһиссәлам: «Кемнең корбан чалырга мөмкинлеге булып та, моны эшләмәсә, мәчетебезгә якынлашмасын»,—дип кисәткән.

**Корбан чалмыйча, чалдырмыйча акчасын гына мәчеткә яки мескеннәргә бирергә ярыймы?**

Корбан чалу–кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбәдәтләрнең берсе. Корбан чалуны акча биреп кылына торган гыйбәдәткә әйләндерү дөрес дип әйтеп булмас.

**Корбанлык өчен нинди хайван сайлау кирәк?**

– Корбанлык өчен пар тояклы–кәҗә, сарык, дөя, сыер кебек хайваннарны алу кирәк. Каз, үрдәк, күркә кебек кошларны, атларны чалырга ярамый. Шулай ук авыру, сукыр, аксак, тешсез, колаксыз, койрыксыз һәм бик ябык яки буаз хайваннарны корбанга чалу дөрес түгел. Сарык һәм кәҗә бер кеше өчен генә корбан кылына, ә сыер яки дөя — җидешәр кеше өчен. Шулай ук бер үзеңә бер сыер, бер дөя корбан кылу да дөрес. Андый ук мөмкинчелеге булмаган кешеләргә бөтен гаиләгә бер корбан чалырга да ярый.

**Нәзер итеп чалына торган корбаннар бар. Монда берәр нинди чикләүләр, халык белеп бетермәгән гамәлләр бармы?**

Нәзер корбанын нәкъ гает көнендә чалу мәҗбүри түгел. Бу эшне башка көнне башкарсаң да була. Кемгә нәзер итеп әйткәнсең, шуңа атап чаласың. Мондый итне үзеңә ашарга ярамый, тулысынча таратып бетерергә яисә кеше җыеп аш үткәрергә кирәк. Үзеңә бары тик шулпасын гына эчәргә була.

**Сыерны корбанга чалганда җиде кеше арасына мәрхүмнәрне кертергә ярыймы?**

Әгәр дә мәрхүмнең калган балалары, я туганнары, якыннары аның исеменнән аерым яки сыер корбанына кушылган вакытта үзен араларына алып корбан чалсалар, гөнаһ түгел, ә саваплы эш кылган булырлар. Мәрхүм исеменнән эшләнгән һәр яхшылык мәрхүмгә чыннан да ирешкәне күп хәдисләрдән билгеле.

**Корбанлыкны ничек дөрес итеп бүләргә?**

Аллаһының илчесе галәйһиссәләм шулай аңлатты: «Ашагыз, ашатыгыз һәм саклагыз». Шуңа да итне өч өлешкә бүлү хәерлерәк. Өчтән берен

бәйрәм табыны әзерләргә, өчтән берен туганнарга һәм мохтаҗларга өләшергә, калган өчтән бер өлешен үз гаиләңә калдырырга. Шулай ук аш үткәрмичә, калган өчтән ике өлешен фәкыйрьләргә, туган-тумачаларга, күрше-күләннәргә таратырга да мөмкин. Ә тиресен исә сатып, акчасын сәдака итеп бирергә була.

**Корбанлыкның яше**

Кәҗә, сарык, куйга бер яшь, сыерга ике яшь, дөягә биш яшь тулган булу шарт, яше ким булганнарны чалу дөрес түгел. Әгәр куй белән сарык бик зур һәм симез булып, бер яшь тулган сарык һәм куйлардан аермасыз булсалар, алты айлыкларны да чалу дөрес булыр, әмма кәҗәгә шиксез бер яшь тулган булу шарттыр. Куй, сарык һәм кәҗә берәр кеше өчен генә корбан кылына, сыер һәм дөя җидешәр кеше өчен корбан чалынса да, дөрес була. Кеше бер үзенә бер сыер, я бер дөя корбан кылса да, дөрес һәм бик саваплы булыр.

**Корбан чалу вакыты**

Корбан чалу гает намазыннан соң үтәлергә тиеш. Әгәр гает намазына кадәр чалынган булса, ул корбан чалу үтәлгән дип саналмый. Корбан чалына торган вакыт: гает намазыннан соң башлап, уникенче Зөлхиҗҗәнең ахшам вакытына кадәр. Бу вакыт эчендә корбан бугазлый алмаган кешегә, әгәр корбанлыгы алынмаган булса, корбанлыкның бәһасен сәдака кылу вәҗиб буладыр, әгәр корбанлыгы алынган булса, ул очракта корбанның үзен сәдака кылу тиеш. Корбанны унынчы Зөлхиҗҗәдә бугазламый калса, унберенче, уникенче Зөлхиҗҗәдә бугазлау да дөрес булыр. Әмма уникенче Зөлхиҗҗәдә Кояш баткannan соң бугазлау дөрес булмас. Әмма көннәр хисабында хаталык һәм бәхәсләрдән котылу өчен, корбан чалуны бәйрәмнең өченче көненә калдырмау хәерлерәк санала. Иң яхшысы – корбанны беренче көндә чалу.

**Кояш баткач, караңгы вакытта корбан чалынамы?**

Корбан чалу - бәйрәм көнен санап, 3 көн дәвам итә. Өченче көннең кояшы баеганчы корбан суюлар тәмамланырга тиешле. Иң яхшысы–бәйрәм көнендә чалып эшен бетерү. Ахшамнан соң корбан чалу –мәкруһ. Хәрам дигән сүз Коръәндә дә, пәйгамбәребезнең сөннәтендә дә юк. Бу–элеккеге заманнарда электр булмаганлыктан, төнлә караңгы вакытта чалу хаталык белән кылынмасын өчен әйтелгән.

**Әгәр кеше кушылган көннәрдә корбан чалып өлгермәсә нишләргә?**

Матди яктан мөмкинчелекле кеше, теләге булып та, вакытында суя алмый калса, бер куй (сарык) сатып алырдый акчасын сәдака итеп мескеннәргә бирер.

**Кайбер гаиләләр корбанны гает намазына кадәр чалып куя. Болай эшләү дөресме?**

Гает укылганчыга кадәр чалынган корбан дөрес булмый. Моның турында пәйгамбәребез дә әйтеп калдырган. «Кем гаеткә кадәр корбан чала, бу аның гаиләсе өчен ит кенә булыр, ә корбан чалу фарызы аның өстеннән төшмәс», -диелә анда.

**Кем корбан чалуны үтәргә тиеш?**

Корбан чалуны исә һәр кеше үзе үтәсә әйбәтрәк. Иң башта терлекне кыйблага каратып яткырырга кирәк. Ул аягында чакта корбан догасы укыла. Аннары «Әй, Раббым! Ошбу хайванны Синең әмерең буенча чаламын. Әй, Раббым! “Кабул кыл. Бисмилләһи, Әллаһү әкбәр!” — дип ниятләп, корбанлык бугазы киселә. Әгәр төрле сәбәпләр аркасында кеше бу эшне үзе башкара алмый икән, башка кешегә тапшырып, карап тора ала. Тик өч шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, бу кеше мөселман булырга тиеш. Икенчедән, корбан чалуны үтәүченең «Әй Аллаһ, бу (корбан) Синнән, һәм Сиңа (кайта), фәләннән кабул ит»,–дип әйтүе кирәк. Өченчедән, ул кешегә чалына торган корбанның ите белән түләргә ярамый.

**Хайванның нинди физик кимчелекләре яки гариплекләре булганда, аны корбан чалырга рөхсәт ителми?**

Беренчедән, ачыктан-ачык авыру хайван; икенчедән, дөм сукыр; өченчедән, аксак; дүртенчедән, ашарга яраклы нинди дә булса әгъзасы (мәсәлән, койрыгы) булмаган хайван. Шуңа күрә мөгезләре киселгән яки печтерелгән хайван корбан чалу өчен туры килә.

**Корбанның сөякләрен күмәргә кирәкме?**

Әгәр сөякләр теләсә кайда ятмасалар, күмү ихтыяҗы юк. Хайванның сөякләре һәм каны ислам буенча изге саналмыйлар.

**Корбанлык ничек бүленә?**

Итне өч өлешкә бүлү хәерлерәк: өчтән берен үзеңә калдырырга һәм бәйрәм табыны әзерләргә, өчтән берен туганнарга һәм мохтаҗларга өләшергә, калган өчтән берен сакларга калдырырга. Түбәндәгечә дә эшләп була: өчтән берен гаиләңә калдырырга, ә өчтән ике өлешен туганнарга, күршеләргә, мохтаҗларга һәм ярлыларга өләшергә. Ә тиресен сатарга, акчасын сәдака итеп бирергә мөмкин. Шулай ук бөтен гаиләгә бер корбан чалырга да ярый.

**Корбан чалганда хайванны кыйбла тарафына юнәлтү вәҗипме?**

Галимнәр моны һәрбер изге гамәл вакытында, хәтта йокы һәм ял вакытында да, кыйблага юнәлүнең мөстәхәб булуы белән аңлаталар. Шулай ук корбан чалганда хайванны саклык белән сул ягына яткырырга һәм башын күтәреп кую мөстәхәб санала.

**Мөһим искәрмәләр**

Җан биргәнгә кадәр хайванны тунарга ярамый.

Дөя яки сыерны корбан чалганда (аны корбан чалуда 1дән 7гә кадәр кеше катнаша ала) барлык катнашучыларның нияте корбан чалу булырга тиеш. Әгәр катнашучыларның берсенең максаты корбан чалудан ит кенә алу булса, йолада катнашучыларның барысының да корбан чалуы дөрес түгел дип санала.

Бер кеше корбанлык алгач, ул корбанлык балаласа, баласы терек хәлендә сәдака кылыныр, яисә анасы белән бугазланыр, ите сәдака кылыныр; яисә балалаган хайван калып, аның урынына икенче хайван бугазланса да, вәҗиб булыр, әгәр дә кеше икенчене алырлык дәрәҗәдә бай булмаса, шунысын да чалырга ярый.

**Эльвира Хәбибуллина әзерләде.**

# Олуг бәйрәм

Бүген күбебез өчен гает бәйрәме мәчеткә барып гает намазы уку һәм аннан кайткач корбан чалу белән генә чикләнеп кала. Пәйгамбәребез һәм аның сәхәбәләре өчен ул чын бәйрәм төсмерен йөрткән. Кунакларга йөрешкәннәр, бер-берсен туганнарча бәйрәм белән котлый торган булганнар, тәмле сыйлар белән сыйланып, Раббыбызга шөкер иткәннәр. Бәйрәм вакытында мәчетләр бизәлгән, аларда төрле чаралар үткән. Риваятьлардан беленгәнчә, бәйрәм көннәрендә мисал өчен Мәдинә мәчете каршында эфиоплар бии торган булган, сәхәбәләрнең балалары биредәге тамашаны күрергә килгәннәр. Пәйгамбәребез әлеге мәҗлесләргә хатыны Гайшәне дә алып килә торган булган. Әлбәттә бәйрәм шулай үтәргә тиеш тә инде. Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә бәян кылынганча адәм баласына хезмәт кылу, кәсеп итү вәҗип булган кебек, бәйрәм вакытында тиешле рәвештә аны үткәрү дә зарур. Шунысын да әйтергә кирәк: бәйрәм көннәре закон нигезендә ял көннәре булмыйча, бу көннәр тулысынча бәйрәм төсмерен ала алмаячаклар. Бәйрәмебезне истә калырлык итеп, сагынырлык итеп ничек үткәреп була соң? Аның өчен бәйрәмнең программасы кызыклы, бай эчтәлекле булырга тиеш. Бәйрәмне үткәргәндә шуны истә тотарга кирәк: бәйрәм ул кешеләрнең күңеленә шатлык бүләк итү генә түгел, ә беренче чиратта динебезнең матурлыгын һәм күркәмлеген белдертү. Бәйрәм көннәрендә киң җәмәгатьчелек өчен төрле дини акцияләр, бәйгеләр, уеннар үткәрү бик күркәм. Әлеге чаралар спорт уеннары белән дә үрелеп барсалар, нур өстенә нур булыр иде. Әлбәттә бәйрәмне рекламалый да белергә кирәк. Шәһәр буйлап тәбрикләүләр, бәйрәмгә чакырулар, афишалар, стикерлар урнаштыру, мәчетләрне бизәү дә уңай нәтиҗәләр бирми калмый. Нигә бәйрәм уңаеннан берәр вәгазьчене, күренекле шәхесләрне чакырып, очрашулар оештырмаска. Ышаныгыз, бу чаралар уңай нәтиҗә бирерләр, үзебезнең динебезнең асылын, бәйрәмнәрнең җәүһәрләрен аңларга ярдәм итәрләр.


## “Дөньяда ниләр бар”

### ГОЛӘМӘЛӘР ШУРАСЫ ҮТТЕ

Диния нәзарәтенең матбугат хезмәтеннән алынган чыганакларга караганда, 2011 елның 19 октябрендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Голәмәләр шурасының чираттагы утырышы үтте.

Көн кадагында ТҖ МДНнең имам-хатыйпларының җомга вәгазьләренә һәм намазларына бәйле кайбер сораулар тора иде. «Голәмәләр шурасында ТҖ МДНның имам-хатыйплары өчен җомга намазлары һәм җомга вәгазьләрен үткәрү тәртибе буенча махсус низамнамә төзелде. Бүгенге көнгә кадәр вәгазьләр буенча низамнамә расланган иде, хәзер без аны, хәнәфи мәзһәбе белән яраклаштырып, җомга вәгазен генә түгел, намазны да берәмтекләп, җентекләп аңлатып, чикләрен тагы да киңәйттек»,–дип билгеләп үтте Голәмәләр шурасы рәисе Рөстәм Батров.

Шулай ук Голәмәләр шурасы тарафыннан ТҖ МДНның нәшрият бүлегендә чыгучы китапларны рецензияләү, ЯАҖ «Тест-Татарстан» Республика сертификацион методик үзәге»ннән җибәрелгән сораулыкка җаваплар әзерләү, Мәскәү «Таяныч» адвокатлар коллегиясенең «Юринформ» №1 Адвокатлар консультациясенә кагы-



лышлы сораулар да каралып үтте.

Болардан кала шулай ук якшәмбе-мәхәллә мәктәпләре өчен өчьеллык уку-укыту программалары расланылды.

### ИМАМНАРНЫҢ БЕЛГЕЧЛЕК ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРҮ ҮЗӘГЕНДӘ НУРЛАТ РАЙОНЫ ИМАМНАРЫ УКУЫ БАШЛАНДЫ

Диния нәзарәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, 17 октябрьдә имамнарның белгечлек дәрәҗәсен күтәрү Үзәгендә Нурлат имамнары укуы башланды. Ике атна дәвамында имамнар гакыйдә, фикһ, гыйбадәт, татар илаһият мирасы, имам вазифалары һәм башка фәннәрне өйрәнде. Аларга лекцияләрне РИУ укытучылары укыды. РИУ каршындагы әлеге Үзәк 19 октябрьдә ачылды.

### КАЗАНДА ВАКФ ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ

«Татар-информ»нан алынган чыганакларга караганда, ТР мөселманнары Диния нәзарәте карамагында булган, Казанның Тукай урамында урнашкан 3 йортта вакф үзәге ачылды. Вакф милке саналган бу бинаны төзекләндерү эшләре 1999 елда башланган. Тарихи архитектура һәйкәле архивларда сакланган эскиз-сызымнар ярдәмендә торгызылган.

### «ЯҢА ГАСЫР» РАДИОСЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БЕЛӘН БЕРЛЕКТӘ «САБЫЙГА» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН ЧАРА ҮТКӘРӘ

Диния нәзарәтенең матбугат хезмәтеннән алынган чыганакларга караганда, 2011 елның 18 октябреннән 18 ноябренә хәтле «Яңа гасыр» радиосы Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә «Сабыйга» дип исемләнгән чара үткәрә. Әлеге чара кысаларында Казанның Киров районы Балалар йогышлы авырулары хастаханәсенә ярдәм күрсәтеләчәк.

### ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАН ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ БЕРЛӘШМӘСЕ АКТИВИСТЛАРЫ ИРАНГА ЮЛ ТОТА

Иртәгә Татарстан мөселман хатын-кызлары активистлары ислам республикасы Иранга кузгала. Биредә алар әлеге илнең тарихы һәм мәдәнияте белән танышачак. Киләчәктә хезмәттәшлек итәр өчен элемтәләр булдырачак. Биш кешедән торган делегация Тегеранда һәм Иранның кайбер башка шәһәрләрендә дә булачак.

**Tatar-islam.ru сайтын кулланып әзерләнде**

## Сорау илә җавап

**Миңа 17 яшь. Әлегә эшләмим. Урамда яки гыйбадәтханәләр янында еш кына хәер сорап торучылар күренә. Аларга сәдака бирергә ярыймы? Бауржан**

Исламда хәер сорану тыелган (хәрам). Җәмгыятьтәге бу авыруның таралуына ярдәм итү шулай ук тыелган. Хәер сорануның хәтта зина кылуга һәм гөнаһлы гамәлләргә тиң итеп каралуы турында хәдисләр бар. Мәсәлән, Мөхәммәд Пәйгамбәр (с. г. в.): «Мохтаҗлык кичермәгән кешенең хәер сорап йөрүе (ул ашарына, эчәренә яисә кияренә әйбер булмаганлыктан соранып йөрми, паразитлык — аның һөнәре һәм шөгыле) Кыямәт көнендә аның йөзендә мәсхәрә булып чагылачак»,-дигән.

Бервакыт Гомәр ибн әл-Хаттаб ахшам намазыннан соң берәүнең соранып йөрүен ишеткән. Ул үзенең бер ярдәмчесенә: “Бу кешене ашат”,-дигән. Күпмедер вакыт узгач, Гомәр тагын бу бәндәнең соранып йөрүен күргән. Ул: «Мин бу кешене ашатырга кушмадыммыни?»-дип сораган. Аңа ярдәмчеләре әлеге бәндәне ашатулары турында әйткәннәр. Икенче хәлифә теге соранып йөрүче бәндә янына килә һәм аның аягы янындагы савытның ипи белән тулы икәнлеген күрә. Гомәр: «Син хәерче түгел, сәүдәгәр икәнсең (ягъни, бу синең һөнәрең)»,-дип аннан ипине ала, аны дөяләргә азык итеп бирә һәм камчы белән кизәнеп: «Башка килмә»,-дип әйтеп, бу кешене куып җибәрә.

Менә сезгә тормыштан алынган бер вакыйга. Бер илдә моннан берничә еллар элек танылган бер актриса Хәйрия эшләрен җәелдереп җибәрде. Аның максаты изге иде: урамда соранып йөрүчеләргә, мохтаҗлык кичерүчеләргә ярдәм итү. Бу эшен башлап җибәргәндә үк аңа хәер соранып йөрүнең зур файда китерүче шөгыль булуы турында әйтәләр. Барыбер урамда хәер соранып йөрүчеләрнең аннан баш тартмаячагы хакында кисәтәләр. Моны ачыклау өчен актрисага фәкыйрь кыяфәтендә киенеп, бер көн буена хәер соранып йөрергә киңәш бирәләр. Ул иптәшләренең киңәшен тотарга була. Бер көн эчендә шактый акча эшләп алгач, бу ханым әлеге шөгыльнең никадәрле керем китерүен аңлый һәм үзенең хәйрия эшчәнлеген туктата.

Димәк, әгәр мөмкинлегегез бар икән, ярлыгы һәм тормыш проблемалары турында үзегез яхшы хәбәрдар булган кешеләргә булышыгыз. Бу эшне туганнарыгыздан һәм якыннарыгыздан башлагыз. Ник дигәндә, изге гамәлләрне нәкъ менә алардан башлау хәерле.

**Кәләшем ислам динен кабул итәргә җыена. Аңа мөселман исемен алу мәҗбүриме? Әгәр шулай булса, бу яңа исем паспортта чагылырга тиешме? Аман**

Бу очракта шәригатьтә исемне алыштырырга дигән сүзләр юк. Ул үзенең элеккеге исемендә калырга мөмкин.

**Сорауларга җаваплар umma.ru сайтыннан алынды.**

# РИЗЫГЫГЫЗ ХӘЛӘЛМЕ?

**Моннан 15-20 еллар элек “хәләл ризык” нииндидер ят төшенчә иде. Хәзер исә татарлар, мөселманнар гына түгел, башка диндәгеләр дә хәләл ит сатып алырга тырыша. Бүген башка диндәге халыклар ни өчен хәләл ризыкка тартыла соң? Җавап бер: ул аларга чисталыгы һәм сыйфаты гарантияләнгән дигән ышаныч уята.**

Хакыйкатьтә, нәрсә хәләл, нәрсә хәрам икәнлеген аңлау һәм белү–кешенең иң олы бурычларының берсе. Чөнки бу мөһим мәсьәләләрне игътибарсыз калдыру Аллаһы Раббыбызның дәһшәтле газабына илтә. Хәләлне билгеләүче нигез буларак Аллаһы Тәгаләнең аяти кәримәсе хезмәт итә. Раббыбыз әйтте: “Мөхәммәд гәләйһиссәлам, , аларны гөнаһлы эшләрдән тыяр һәм саваплы эшләргә өндәр, яхшы, пакъ нәрсәләрне аларга хәләл кылыр, зарарлы, пычрак нәрсәләрне аларга хәрам кылыр...”

**“Дуңгыз булмаса, барысы да хәләл”,–дигән фикер дөресме?**

Аерым ит мәсьәләсенә килгәндә, дөресен әйтик бүген безнең халык: дуңгыз булмаса, барысы да хәләл, чөнки бу хайваннар тыелмаган”, – дигән төшенчә белән яши. Ул тере килеш хәләл, әлбәттә, ә мөселман кануннары буенча суелмаган икән, ул берничек тә хәләл була алмый. Бездә дә: “Ат ите хәләл түгел икән, сыңар тояклы хайваннар хәләл була алмый”, – дигән фикерләрне ишетергә туры килә. Бу мәсьәләгә ачыклык кертеп шуны әйтергә була, пәйгамбәребез заманында ат сугышта корал вазыйфасын үтәгән. Бу вакытта ат суюны тыеп торганнар. Хәрам булганы өчен түгел. Сугышта җиңү яулау атның санына бәйле булган. Ә бүген исә сугыш чарасы буларак атка ихтыяҗ юк.

**Кәнфит хәрам була алamы?**

Гадәттә без хәләл ризык дигәндә, итне генә күз алдына китерәбез. Бактың исә, алай гына түгел икән. Кәнфит, прәннек, торт кебек без яратып ашый торган татлы ризыклар да хәләл булмаска мөмкин. Дөрес, кайберәүләр моны чиктән тыш кылану, халык башын бутау, дияр. Әмма көн саен ашаган ашамлыкларыбызның нәрсәдән ясалганын, нинди матдәләр кушылганын белеп бетерә алмыйбыз икән шул әле. Кондитер әйберләре, гадәттә, оннан, майдан ясала, эчендә төрле кайнатмалар була. Әлбәттә, бүген бик сирәк җитештерүчеләр генә чип-чиста кайнатма ясыйлар. Еш кына, кайнатмага аракы, шәраб кушалар. Ә ризыкның составын карасаң, кайнатма (начинка) дип язылган. Мәсәлән, аракы кушмасаң, тортның сыйфаты булмый, бик тә коры була. Аның составында аракы юк, дип язылса да, ул бар. Ә хәләл торт ясаганда, юеш булсын өчен, төрле ысуллар кулланалар. Әгәр составында шөбһәле кушылмалар күрәбез икән, андый ашамлыкларны кулланмау хәерлерәк. Пәйгамбәребез, хәләл дә, хәрам дә билге¬ле, ди. Алар катгый рәвештә билгеләнгән. Араларында шөбһәле әйберләр дә бар. Әгәр син, бүген, иртәгә монысы ярый, дип шөбһәләнгән әйберләрне кулланасың икән, син хәрамгә якынаясың дигән сүз. Шуңа күрә пәйгамбәребез шөбһәле әйберләрдән читләшергә куша.

**Хәләл төшенчәсе–киң төшенчә**

Татарстан Республикасы Диния нәзарәте каршындагы “Хәләл” комитеты рәисе Динар Садыйков әйтүенчә хәтта су, йомырканы да хәләл тамгасы белән чыгаручы оешмалар бар. Ул шуны да искәртеп үтә: “Үзебезнең тәҗрибәләргә таянып, шуны әйтә алам: катнаш булган һәрбер ризык та хәләл раслану үтәргә тиеш. Башка илләрдә бу тиеш түгелдер, ләкин Россиядә катгый рәвештә тикшерелүе зарур. Дуңгыз итен турыдан-туры ашамыйбыз икән, безнең организмга аның мае катнашма рәвешендә керергә мөмкин. Алыйк чипсыны. Аның составында бәрәңгe һәм майдан башка нәрсә булырга мөмкин, дип уйлыйбыз инде. Ароматизатор, консервантлар була. Хәрам булырлык бернинди кушылмалар да юк кебек. Бактың исә ароматизаторны, бәрәңгенең нинди майда кыздырылуын тикшерә башласаң, чипсының хәләл түгеллегенә инанасың. Көнбагыш маенда гына түгел, ә яхшырак кызсын өчен, аңа берникадәр дуңгыз мае кушып җибәрәләр икән. Яшел суган һәм каймаклы чипсының составын тикшерергә туры килде. Эчендә дуңгыз мае бар. Халык аны белеп бетерми. Әйтик, маргарин. Ул үсемлек мае кушып ясала, шулай ук хайван маен да катнаштырырга мөмкиннәр. Моны йөз процент хәләл дип әйтә алмыйбыз. Майонезга да хайван мае кушыла. Аннан майонезга кушыла торган күкәйне генә алыйк. Гадәттә, табигый түгел, ә корытылган, модификацияләнгән йомырка кушыла. Ә ул ике төрле ысул белән эшләнә. Берсе бактерия белән, ә икенчесе дуңгызның ашказаны асты бизе белән ясала. Ә бит йомырканың шундый ысул белән ясалганын берәү дә язмый”.

**“Хәләл” кафе–кайчан исеме җисеменә туры килер?**

Хәзер “хәләл” исеме астында бик күп кафелар, ашханәләр эшли башлады. Аларның кайберләренең хәләллеккә сертификаты бар, кайсыларыныкы юк. Без еш кына, хәләл ризык әзерлибез, дип сүз белән әйтүче кафе, ашханә хезмәткәрләренә тиз ышанабыз. Оешма сертификатсыз икән, бу мәсьәләгә күбрәк игътибар итү бик зарур. Шуныcы кызык: татар, үзбәк милләтеннән булучылар, үзләрен мин мөселман дип санап, ризыкларын хәләл дип уйлый. Әмма итне каян алган, кем аны суйган? Ул моны белми. Сорый башлагач, базардан алдым, дип җавап бирә. “Хәләл” комитеты рәисе Динар Садыйков әйтүенчә, “бүген базарда хәләл ит очрату бик сирәк күренеш. Суйганда бәлки хәләлдер дә ул, әмма базарга барып җиткәнче, күпме куллар, арадашчылар аша үтә. Хәләл белән гадәти ит буталып бетә, ә аны буталмаган дип кем әйтә ала? Бер кеше әзәрбайҗан ресторанына кергән дә: “Монда ит хәләл түгел икән, ярар алайса, балык бирегез”, – дигән. Ашап карагач, бик тә майлы тоелган һәм официанттан кызыксынырга булган. Балыкка тәм бирер өчен, өстенә дуңгыз мае кыздырып салдык, дигәннәр моңа. Шулай итеп, хәләл булган балык ризыгы да хәрамгә әйләнде. Шуңа күрә ризык тикшерену үтәргә тиеш. Әйтик, бөтен яшелчә, җиләк-җимешне дә хәләл дип әйтеп булмый. ГМО хәрмнәрдән санала. Кибеттә сатылган ризык табигыйммы, әллә ГМО рәвешендә үстерелгәнме? Димәк, кибетләрне дә тикшерергә кирәк”.

**Сак булыгыз: “Хәрам”!**

Хәрам ризык белән ризыкланган кешенең бу дөньяда догасы кабул булмый, кыямәт көнендә исә ул кешегә җәһәннәм газабы булачак. Әбү Хөрәйрадан риваять ителә ки, Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм әйтте: “Бер кеше Раббысына ялвара, кулларын күтәреп дога кыла: “Ий Раббым, ий Раббым”,–ди. Әмма аның ашаган ризыгы хәрамнан, эчкән суы хәрамнан, кигән киеме хәрамнан, ничек Аллаһы Тагәлә аның догасын кабул итсен”. Шулай ук Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: “Хәрамнан төзелгән җисем бары тик утка гына лаеклы”, - дип әйтте. Димәк, догабыз кабул булсын, Аллаһ газабыннан ерак булыйк дисәк, бары тик хәләл ризык кына кулланыйк. Йөзебез нурлы, тормышыбыз бәрәкәтле булыр.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

# МӨСЕЛМАННЫҢ КҮЗ ЯШЕ

**Күз яшьләре кайгыдан, сөенечтән дә чыга. Шулай ук алар кешенең йомшак күңелле, хисле икәнлеген дә билгели. Яшьләр хәтта кешенең рухи һәм физик халәтен бәяли.**



Мөэминнең гыйбадәт кылганда чыккан күз яшьләре аеруча игътибарга лаек. Нәкъ менә шул әнҗе бөртекләре Аллаһы Тәгалә каршында кыйммәтле. Кыямәт көнендә алар өчен коллар чиксез нигъмәтләргә ия булачак.

Бер хәдистә «Өч кеше иблистән һәм аның гаскәреннән котылачак: тәүлек буена Аллаһыга зикер әйтүчеләр, төннең икенче яртысында Аллаһтан куркып елаучылар һәм кылган гөнаһлары өчен чын күңелдән тәүбә итүчеләр», –диелә.

Бу кешеләр бер төркемгә бүленеп, төнен һәм көнен Аллаһны искә алалар: «Ләә иләһә илләллаһ». Төнлә торып: «Әстәгъфируллаһ әл-әзим, әстәгъфируллаһ әл - әзим»–дигәндә аларның күз яшьләре чыга.

Әгәр дә күзләр Аллаһтан куркып яшьләнә икән, шул чакта җәһәннәм уты башка әгъзаларга да кагылмас. Әгәр дә күз яше яңакка тама икән, бу кешенең битенә кара төшмәс. Өммәт эчендә бер генә кеше Аллаһтан куркып елый икән, бу өммәтне Аллаһы Тәгалә төрле бәлаләрдән саклар.

Тик бөтен нәрсәнең дә үз үлчәме бар. Бу күз яше бернәрсәгә дә охшамаган. Бер күз яше белән диңгез зурлыгындагы ут учагын да сүндереп була. (Рамуз әл - Әхадис,№ 4587 әйтем).

Ибн Хиббән Сәхихендә язылган: «Мин, УбайдуЛлах ибн Өмәйр, Гайшә (р.г.) янына кердем һәм әйттем: «Сез Пәйгамбәр (с.г.в.) кылган иң күркәм гамәл турында әйтегез әле». Гайшә елап: «Бервакыт ул төнлә намаз укырга торды һәм миңа: «Гайшә, мине ялгызымны гына калдыр әле гыйбадәт кылырга»,- диде. Мин: «Аллаһ белән ант итәм, мин синең янәшәңдә булырга яратам. Сине бәхетле кылган гамәлләр мине дә шатландыра»,-дидем. Ул тәһарәт алып, намаз укырга җыена башлады. Гадәттә, намаз укыганда аның тезләре, хәтта тирәсендәге җир дә дымлана иде. Шул вакытта азан әйтмәкче булып, Билал керде һәм Пәйгамбәрнең күз яшьләрен күреп: «Син ник елыйсың, Аллаһы синең булган һәм булачак гөнаһларыңны кичерде бит?»- диде. Ул: :«Мин рәхмәтле кол булырга тиеш түгелме? Бу төндә миңа берничә аять индерелде. Кем дә кем намаздагы аятьләрнең мәгънәсен белмичә укый икән, шуның хәле бик тә аяныч»,–дип әйтте.

Безгә Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тормышы үрнәк булып торырга тиеш. Кызганыч, хәзерге заманда безнең күпләребез аның елыйелый намаз укыганын истә тотмый, бик азларыбыз ихластан гыйбадәт кыла.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

---

## СОРАУНЫҢ ҖАВАБЫ

**Намазга дип билгеләнгән вакытның яртысы узганнан соң укылган намаз фарызны үтәү генә булып санала, ә аңа савап намаз азан әйтелгәч тә укылса гына тулысынча языла, кичектереп укылганда савап кими диләр. Дөресме бу?**

Намазга дип билгеләнгән вакыт кысалары бу гыйбадәтне төрле вакытта уку мөмкинлеге бирә. Әмма Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) хәдисләреннән күренгәнчә, намаз укуның иң хәерле вакыты булып, аның вакыты керүгә җәмәгать белән укылганы санала. Бу очракта, әгәр сез намазны дөрес укымаганлыгыгызны белсәгез, аны яңадан укырга да вакыт кала. Дөрестән дә, кичектереп укылган, ләкин вакыты чыкмаган намаз өчен савап кими, чөнки мөселман кешесе гадәттә аны вакыты керүгә укый. Ә намаз җитди сәбәпләрдән тыш, соңга калып укылса, кешегә Аллаһының бүләге дә ниятенә, тырышлыгына карап бирелә.

**Фикһ китапларында җәмәгать белән укылган намаз вакытында имам артыннан кешегә ишетелерлек итеп тә, үз эчеңнән дә кабатларга ярамый диелгән. Бу 3-4 рәкәгатьле фарыз намазлары вакытында, 2 рәкәгатьле намазларда «Фатиха»ны укымаска, дәшмичә генә торырга дигәнне аңлатамы?**

Әйе, хәнәфи мәзһәбе буенча җәмәгать белән укыла торган намазларда имам фарыз намазларын кычкырып укыса да, укымаса да, аның артыннан кабатларга кирәкми. Ник дигәндә, аның кылган гыйбадәте сезнең кылган гыйбадәтегез булып санала.

**Икенде намазын кайчан уку хәерлерәк?**

**Икендене вакыты кергәннән соң, аны бераз соңрак укырга кирәк дип ишеттем. Тик мәкруһ булмасын өчен сөннәт намазларын укуны кайчан туктатырга һәм фарызны кайчан башларга? Дөресрәге, кояш баерга күпме вакыт калгач, фарызны укып була?**

Әгәр сез икенде алдыннан өстәмә намазлар укырга теләсәгез, аларны кояш кызара башлаганчы ук тәмамларга тиеш буласыз. Ни өчен дигәндә, бу фарыз намазын дөрес укымаган очракта аны дөресләргә вакыт калдыру максатыннан шулай эшләнә. Асылда, икендене мәчетләрдә билгеләнгән тәртип нигезендә, вакыты керү белән үк уку хәерлерәк.

**Ислам динен кабул итүче кәләшемә мөслимә исемен алу мәҗбүриме?**

**Әтием–мөселман, әнием –православие динендә. Мин дөньяга килгәч, мулла колакка азан әйткән, ә берничә көннән әни чиркәүгә алып барып, чукындырган. Мин ислам динен кабул итеп, мөслимә була аламмы? Бер тапкыр динеңне алыштыргач, инде исламга кайта алмыйсың, дип ишеткәнем бар. Ә бит динемне минем ихтыярдан башка гына алыштырганнар. Үземне мөслимә дип саныйм, шулай да бу мәсьәлә мине бик борчый. Миңа нишләргә? Яңадан мәчеткә барып, ислам динен кабул итәргәме? Алия**

Биредә кайсы динне сайлау сезнең үзегездән тора. Иман кәлимәсен әйтсәгез һәм исламның 5 баганасын кабул итсәгез, мөслимәгә әйләнәсез.

Минем «Мусульманское право 1 - 2» дигән китаптагы «Принятие ислама» дигән язманы укысагыз, ничек мөселман булырга дигән сорауга җавап табарсыз.

**Сорауларга җаваплар umma.ru сайтыннан алынды.**

# “ФЕН-ШУЙ”– БУШ УЙ



**Соңгы вакытта багучылык, төрле секталар, мона кадәр күренмәгән сәер юнәлешләр, алдагысын әйтеп бирү күренешләре киң таралды. Теләсә нинди газетаны ачуга шундый белдерүләр күзгә чалына: “Күрәзәче сезнең язмышыгызны сөйләп бирер” яки “Тәҗрибәле астролог киләчәкне юрый”. Белдерүнең “Югары категорияле сихерче сезнең өчен көн саен йолдызнамә төзи”, «Проблемаларыгызны хәл итәбез» кебекләре дә бар. Телевизорны ачсак та, “йолдызлар фаразы” әйтәләр. Һәр журналда атналыкмы, айлыкмы йолдызнамә бирелеп бара.**

Бүгенге газета - журналларда, телевидение һәм интернетта түбәндә эчтәлекле белдерүләр бихисап: “алдагысын сөйләп бирәм”, фен –шуй сезнең язмышыгызны үзгәртә, сезгә бәхет, байлык китерә һәм башкалар. Миллионлаган данәдә күрәзәчелек, багу һәм сихергә өйрәтә торган, фен-шуй мисалындагы дингә каршы килә торган китаплар бастырыла. Шуңа күрә, теләсә кем шушы деструктив юнәлешләрдән хәбәрдар була ала. Еш кына кешеләр, авыр хәлгә юлыккач, югалып калалар. Кая барып бәрелергә, кемгә мөрәҗәгать итәргә белмәгәнлектән, соңгы чарага - багучыларга, экстрасенсларга һәм башка “белгеч”ләргә мөрәҗәгать итәләр. Аларга өметләнәләр, аларның ниндидер серле көче барлыгына чын күңелдән ышаналар. Бу очракта бер хакыйкатьне онытмаска кирәк: бары тик Аллаһы Тәгалә генә кешеләрнең язмышларын, алдагысын белә. Бу сүзләргә дәлил Коръәндә бирелгән: “Яшерен нәрсәләрне белү ачкычы Анда гына, Аннан башка беркем дә аларны белми” (27:65) яки “Яшерен нәрсәләрне белүче, Илчеләрнең кайберләреннән башка, беркемгә дә бу серләрне ачмый” (72:26-27).

Җәмгыятьтә көннән-көн яңа секталар, төрле юнәлешләр барлыкка килүе, әлбәттә бик аяныч күренеш, чөнки кешеләр бу ялган һәм куркыныч төркемнәргә ияреп үзләрен хакыйкый диннән ераклаштырып, Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булалар. Моннан да куркыныч нәрсә бар микән? Юктыр мөгаен. Раббыбыз кемгә дә булса ачуланса, ул кешене үзенең рәхмәтеннән өзүе көн кебек ачык. Бөек хуҗабызның рәхмәтеннән коры калу ул бар нәрсәдән коры калу дигән сүз. Шушындый Аллаһ рәхмәтеннән ваз кичтерә торган ялган тәгълиматләрнең берсе–фен-шуй тәгълимате. Кыскача, фен-шуй ул мәҗүсилек философиясе, һәм әлбәттә ислам дине белән бернинди дә уртаклыгы булмаган, аңа гомумән ят булган тәгълимәт. Нигә шулай? Җавап шунда ки Ислам дине төрле сынамышларны, йолдызнамәгә ышануларны, нинди дә булса сыннарга табынуларны тыя. Шуның белән берлектә җилнең, кояшның, янгырның һәм башка табигать күренешләренең Аллаһтан башка хуҗасы бар дигән игътикат Ислам динендә юк. Барлык әйберләрнең хуҗасы бары тик Аллаһ–бу Ислам динендә урын алган бөек хакыйкатьләрнең берсе. Ә фен-шуй сектасында без моңа капма -каршы булган әйберләрне күрәбез. Мисал өчен ошбу алдавыч юнәлеш әһелләре төрле –төрле сыннарга, таштан яки башка әйбердән эшләнгән бернинди дә файда китерми торган сүрәтләргә үзләренең ширки мөнәсәбәтен белдерәләр: аларны үбәләр, ихтирам итә, алардан нәрсә дә булса сорау, үтенү төсмере белән аларга мөрәҗәгать итәләр. Югыйсә, без бар әйберне дә бары тик Аллаһ Раббыбыздан гына сорарга тиеш түгелме? Араларыннан аерата акыллылары: “Без Аллаһның бер икәнен беләбез, ана гына табынабыз, ләкин арадашчы сыннарыбыз-таштан ясалган, авызына тимер акча каплкан бакалар аша, башка сыннар һәм сүрәтләр аша без Раббыбызга үзебезнең догаларыбызны ирештерәбез”,–диләр. Үрдәктән мәхәббәт бирә дип көтү, кара ташбака аша карьераңны яхшырту, яшел аждаһадан сәламәтлек һәм гаилә бәхетен көтү–болар барысы да башка сыймый торган нәрсәләр. Бу әйберләргә акылы тар булган, башы белән дус булмаган кеше генә ышана ала диясе килә. Әмма иң кызганычы шулдыр ки, фен-шуй әһелләре арасында укытучылар да, инженерлар да һәм бер генә түгел, ә берничә югары белемле кешеләр бар. Моны нәрсә белән аңлатып була соң? Беренчедән, фен-шуй белән иманы сай булган кеше генә шөгыльләнә ала. Димәк үз динеңне белмәү, аның белән кызыксынмау, өйрәнергә теләмәү, гомумән Аллаһы Тәгаләдән ерак булу бу аяныч хәлләргә китерә ала. Икенчедән, бүген рухи кыйммәтләр югалган мәлдә кешеләр байлыкка һәм гомумән “бәхеткә” ирешү өчен бар нәрсәне дә эшләргә әзер, бүгенге кеше малга, дәрәҗәгә, нинди дә булса статуска ирешү өчен бернинди дә ысуллардан чирканмый. Аның үз нәфесенә кол булуы Коръәнгә каршылыклы булган ысулларны да кулланырга әйдәкли. Фен-шуй шуның белән дә куркыныч: ул кешене милләтеннән, милли йолаларыннан, сәнгатеннән, традицияләреннән читләштерә ала. Ә иң куркынычы: кешене җәһәннәмгә илтә. Әмма, хакыйкатьтә байлыкны да, барча нигъмәтләрне дә Аллаһ кына бирүче. Бу сыннар, сүрәтләр исә сәнгать үрнәкләре генә булып торалар. Кызганыч ки фен –шуй иярченнәре моны аңларга һич теләми бугай. Аңлаган булсалар төрле билгеләмәләрнең, символларның, буддаларның, талисманнарның нинди дә булса мәнфәгать китерүенә ышанмаслар иде. Дөресен әйткәндә бу әйберләр кешене түгел, хәтта үз-үзләрен дә саклый алмыйлар түгелме соң? Югыйсә аларны ватып–җимереп булмас иде бит. Ничек инде үзләрен дә яклый алмаган әйберләр безнең язмышыбызны хәл итә алсын ди? Монда шуны да онытмаска кирәк: күрәзәчеләргә ышанган кеше аларга психологик яктан бәйле була. Ул бәйлелек һаман саен арта бара ки, кеше фен-шуй закончалыкларына гына карап, үзе бернәрсә дә уйламый башлый, иреген, фикер хөрлеген югалта. Йолдызнамәгә, фен-шуй кебек тәгълиматләргә генә табына башлый. Шуның өчен дә, Ислам дине мондый түбәнчелекле коллыкның рухны зәгыйфьләндерүен искәртә һәм ошбу әйберләргә ышануны тыя.

**(Ахыры 8нче биттә.)**

# “ФЕН-ШУЙ”– БУШ УЙ

(Ахыры. Башы 7нче биттә.)

**АСТРОЛОГИЯ ЯЛГАНГА НИГЕЗЛӘНГӘН**

Фен-шуйнин дидердәрәҗәдә астрология белән дә бәйле. Ислам динендә бу да ярамый. Астрология, йолдызнамә белән шөгыльләнү генә түгел, ә экстрасенслар янына бару, күрәзәчеләргә ышану, йолдызнамә уку, астрология буенча китаплар сатып алу да тыела! Чираттагы газетадан үз йолдызнамәсен эзләүчегә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) түбәндәге сүзләрен җиткерәбез: “Кем багучы янына килеп, нәрсә булса да сораса, аның намазы 40 көн буена кабул булмый”. Бу хәдис Мөслим җыентыгында китерелә.

Йолдызнамәләргә ышанган кешене кяфергә дә тиңләү бар. Чөнки Мөхәммәд (с.г.в.) бу уңайдан болай дигән: “Кем сихерче һәм багучыга барып, аларга ышана, шул имансызлык белдерде дигән сүз”. Ошбу хәдис Әбү Хөрәйрә, Әхмәт белән Әбү Давыт җыентыкларында да бар.

**БАГУЧЫГА БАРМА, БАШЫҢА БӘЛА АЛМА**

Багучылыкка килсәк, кайбер бәндәләр, киләчәкне Аллаһтан башка беркемнең дә белмәвен онытып, багучыларга һәм башка алдакчыларга ышаналар. Шуңа күрә сихерчеләр, им-томчылар, күрәзәчеләр бүген бик популяр. Ислам динен белмәү халыкны багучыларга китерә. Югыйсә кыен вакытларда Аллаһка мөрәҗәгать итәргә, Аңа гына догалар кылырга кирәк. Багучылык – алдау ул. Кызганыч ки, тикшерү органнары бу өлкәдә бер статистик мәгълүмат та бирмиләр. Бүген исә меңәрләгән багучы, сихерче кеше алдалап, акча эшли. Ләкин кайбер мөселманнар да бернәрсә дә белмиләр, шушы багучыларга, сихерчеләргә, алдакчыларга йөриләр. Алар мөселманның киләчәк язмышы хакында сорарга тиеш түгел икәнлеген оныталар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дигән: “Язмыш хакында сөйләгәндә, сез сөйләшмисез”.

Шуны да аңларга кирәк, багучылык – шайтан гамәле, моның хакында Аллаһ Үзе әйтә: “Әй, иман китергән бәндәләр, дөреслектә, шәраб, отыш уеннары, потлар, багучылык - шайтан гамәлләреннән булган начар эшләр. Алардан саклагыз” (Маидә, 90).

**ЮК-БАРЛАРГА ЫШАНУ –АЛЛАҺНЫҢ АЧУЫН ЧЫГАРУ**

Юк-барга ышануга килсәк, кайбер бәндәләр сынамышларга ышаналар. Мондый сүзләрне ишетергә туры килә: “юлны кара мәче кисеп үтте”, “каршыга буш чиләкләр күтәргән кеше килә”.

Исламга хәтле чорда бөек кешеләр үлгәч, кояш һәм ай тотыла дип әйткәннәр. Пәйгамбәребезнең Ибраһим исемле улы үлгәч, кояш тотылган. Кешеләр моны Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) улы үлгәнгә дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Моны пәйгамбәр белгәч, намаз укыганнан соң, болай дигән: “Кояш белән Ай – Аллаһның билгеләре. Үлем белән туу аркасында гына кояш белән ай тотылмый”. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә мондый сүзләрне дә китергән: “яман сынамышлар – ялган, елый торган ябалак – ялган, сәфәр аеның уңышсызлыгы –ялган” (Бохари, Мөслим).

Сынамышларга ышанган кеше соңыннан боларның ялган икәнлеген ачыклый. Юк-барларга ышану кешенең акылын томалый.

Шуны әйтергә кирәк, әлбәттә, фен-шуйның файдалы яклары да бар: тәртип саклау, бүлмәләрне чиста тоту, аларны матурлау һәм бизәү. Әмма шуны аңлау тиешле: өйдә әйберләрне күчереп куеп кына безнең язмыш үзгәрмәс. Белү зарур: Аллаһтан хәерле язмыш сорап һәм шәригать тыймаган ысуллар белән тырышлык күрсәтеп кенә чын бәхеткә, Раббыбызның ризалыгына ирешеп була. Шуны онытмыйк, иманнын мөселман гомере буена саклый. Аллаһка ышану гына бәхет, котылу китерә.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН**

---

# Фани дөнья–бары бер мизгелдер...

**“Ий мөэминнәр! Аллаһыга итәгать итегез. Пәйгамбәргә һәм үз арагыздан сайлап куелган идарәчеләрегезгә буйсыныгыз”. (“Ниса”, 59)**

Барыбыз да бүген күп беләбез,–
Булган,–дибез–гореф–йолабыз.
Гореф-ґадәт әле бит дин түгел,
Бары Коръән–безнең кыйблабыз!
Әби-бабаларыбыз
динне саклаганнар,
Ләкин килә алды микән ялгышсыз?
Туры юлны, чын хакыйкатьне
Аллаһ Китабыннан сез табарсыз.
Имам гамәленә чын мөселман,
Коръән укып фикер йөртәчәк.
Үзенең кылган хатасына имам,
Бер ялгызы җавап тотачак.
Тик хакмы ул, әллә ялгышамы–
Җитәкчегә кирәк буйсыну.
Имамга ияргән барлык гамәл
Дөрес булып кабул булачак.
Имамны үзегезгә сез сайладыгыз–
Ә ул булды Аллаһ тәкъдире.
Ахирәттә һәрбер имам
Мәхәлләсе өчен җавап бирер.
Мәчеткә сәдака сала алмыйбыз,
Тикшерәбез мулла кесәсен.
Утка, газга, салым түләргә кирәк–
Уйлый белмибез аның нишләсен!
Белсәк иде мәчет, мәдрәсә, юлга
Биргән сәдаканың савабын!
Юкка гөнаһ җыймыйк,
һәр сорауның
Табарбыз без бер көн җавабын.
Мәҗлесләрдә Коръән
аятьләре тыңлап,
Акча алмаштырып уйнамыйк.
Үзебезнең гамәлләрне барлыйк,
Кеше гөнаһларын урламыйк.
Фани дөнья бары бер мизгелдер–
Ике каш кебек якын әҗәл арасы.
Изге гамәлләрне кылып карыйк,
Барыбыз да шунда барасы!

**ӘЛФИРӘ ХАҖИЕВА.**

## Белдерүләр

Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Корьән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485

Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мәрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур. 8/28)

Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**